КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

14.04.2026 №62-п

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 9 июлендәге 149-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 9 июлендәге 149-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Э.Ф. Әхмәтовага» сүзен «И.Ф. Миргалимовка» сүзенә алмаштырырга;

күрсәтелгән Боерык белән расланган «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Комиссиясе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Агентлыкның норматив хокукый акты нигезендә төзелә. Күрсәтелгән акт белән Комиссия составы, һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия

Рәисе, аның урынбасары, секретарь һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләп куела.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара..»;

2.2 пунктның «а» пунктчасында «(Комиссия рәисе),» сүзләреннән соң «Агентлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары),» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

3.1. пунктның «а» пунктчасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәткәренең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәдә каралган белешмәләрне дөрес итеп һәм тулысынча тапшырмавы турында;»;

3.11 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) дәүләт хезмәткәренең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәдә каралган белешмәләрне дөрес  һәм тулы дип билгеләргә;»;

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр  буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Комиссиясенең күрсәтелгән боерык белән расланган составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр буенча
республика агентлыгының
2024 елның 9 июлендәге 149-п
номерлы боерыгы белән расланды
(«Татмедиа» матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр буенча
республика агентлыгының
_______________ боерыгы редакциясендә)

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составы

**Комиссия рәисе**

| | |
|---|---|
| Миргалимов Илдар Флүс улы | «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |

**Рәис урынбасары**

| | |
|---|---|
| Василова Диана Әнвәр кызы | «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |

**Комиссия секретаре**

| | |
|---|---|
| Сметанина Анна Александровна | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы баш белгече |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Гарифуллин Васил Заһит улы | Казан (Идел буе) федераль университетының Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институты Журналистика һәм |

| | |
|---|---|
| | медиакоммуникацияләр югары мәктәбенең милли һәм глобаль мидиа кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Корсуков Михаил Николаевич | «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының юридик секторы мөдире |
| Латыйпова Гүзәл Рәшит кызы | «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының кадрлар бүлеге башлыгы |
| Лохотской Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге баш киңәшчесе (килешү буенча) |